**Татарстан Республикасы Ютазы муниипаль районы Советы**

**КАРАР №11**

III чакырылыш XXVI утырышы Урыссу ш.т.б. “29” апрель 2019 ел

*Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2009 елның 21 маендагы 169 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ижтимагый советы турындагы нигезләмә хакында" гы I чакырылыш XXVII утырышы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында*

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2009 елның 21 маендагы 169 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ижтимагый советы турындагы нигезләмә турында"гы I чакырылыш XXVII утырышы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) «Ижтимагый советның максаты һәм бурычлары» дип аталган 2 бүлекне түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:
«коррупциягә каршы көрәштә үз вәкаләтләре чикләрендә катнашу»;

2) “Ижтимагый совет функцияләре" дип аталган 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыруда катнаша".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә htt://pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми портал”ында һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының http//jutaza.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштырырга (халыкка игълан итәргә).

Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән ун көн узгач үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы башлыгы –
Ютазы район Советы Рәисе Р. М. Нуриев